ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.10.2025 г. Заинск № 478

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары балаларын ташуны оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2026 елга нормативларын раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 05 июлендәге 545 номерлы карарының 2 пункты нигезендә «Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары балаларын ташуны финанслау нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәр раслау турында» һәм Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Түбәндәгеләрне расларга:

2026 елга гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән ташу оешмалары тарафыннан гомуми белем бирү оешмалары балаларын ташуны оештыру өчен муниципаль хезмәт күрсәтүләр бәясен исәплəп чыгару тәртибе турында нигезләмә.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары нигезендә финанслау.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына» һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

М.В. Валиахметова
9-90-16

Татарстан Республикасы Зәй
муниципаль районы Башкарма
комитеты карары белән расланды

№ 478 "15" 10 2025 елдан

2026 елга гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елына сум | автотранспорт чарасының бер чакрым йөгерешенә ставка, елына сум |
| КАВЗ | 1 177 194,49 | 28,27 |
| ПАЗ | 1 177 451,99 | 28,42 |
| ГАЗ «Газель» | 1 155 206,40 | 18,17 |
| УАЗ | 1 154 753,20 | 16,08 |
| FIAT | 1 158 244,90 | 13,29 |
| Peugeot Boxer | 1 163 580,30 | 12,88 |
| Ford Transit | 1 163 837,80 | 18,29 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 1 179 388,39 | 25,07 |

Татарстан Республикасы Зәй
муниципаль районы Башкарма
комитеты карары белән расланды

№ 478 "15" 10 2025 елдан

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балалар ташу өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәя нормативларын исәпләү тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларына йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакын исәпләү механизмын (алга таба - муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының фактта узган юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакы нормативлары ел саен «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактта узган юлы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча хисап елында автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында автотранспорт чарасының фактта узган юлы буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. i-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ - муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ -m моделле автотранспорт чараларының факттагы үткән юлы, километр ;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру бәясе ставкасы, бер километрга, сум;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән ташуны оештыру бәясенең бер автотранспорт чарасына, бәя нормативы ставкасы, сум;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чаралары саны, *берәмлек*;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделенең номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.